ЯЗМЫШ БОРЫЛМАЛАРЫ

Фәрит Мөхәммәтшинның юбилее уңаеннан яңа китап тәкъдим ителде

> 2

СӘХНӘДӘ – «ИРДӘҮКӘ»

Камал театрында – тарихи премьера

> 3

БЕЛЕП ҮССЕННӘР

Сәрия Сафина өендә музей ачкан

> 3

ӘЛЕГӘ ХУШЛАШМЫЙЛАР

«Рубин» командасы кая барып чыгар?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 71 (28844) | Сишәмбе | 24 май | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

УРТАК ШАТЛЫК

«ИЗГЕ БОЛГАР ҖЫЕНЫ» 20 МЕҢЛӘП КЕШЕ КАТНАШЫНДА УЗДЫ

Дөнья белән бәйрәм иттек. Узган шимбәдә мөселманнар Болгар җирендә ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп узды. Эстафета Мәскәүгә күчә, бәйрәм чаралары анда да узачак. Оештыру комитеты утырышы, һавадан яуган бәрәкәт, бәйрәм рухы, теләкләр ташы, рәхмәт сүзләре – «ВТ» әлеге тарихи вакыйга үзәгендә кайнады.

tatarstan.ru

Матур эшләребез бар

1100 еллыкны зурлап, федераль дәрәҗәдә үткәрү мөһимлеген Россия Президенты Владимир Путин да һәрдаим искәртеп торды. Аның ярдәме белән федераль оештыру комитеты булдырылды. Алар куйган максатларга ирешкәнме? Болгар җирендә ел дәвамында башкарылган эшләргә хисап тотып, алдагыларына хәер-фатыйха алдылар.

Эшләрнең күпчелеге төзелешкә бәйле булуы белән берәү дә бәхәсләшмәс. Казандагы Җәмигъ мәчете нигезенә таш салу шул әһәмиятле чараларның берсе булды. Бу хакта Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин да искәртте.

– Юбилей датасында инфраструктура проектларын тормышка ашыру кысасында күп эш алып барылды. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең яңа корпусы төзелеше тәгәлләнеп килә, Мәскәүдәге мәчет һәм мәдрәсә биналарын төзекләндерү буенча документ эше алып барыла, Болгарда кайбер корылмалар, юл төзекләндерелә, Кырымда зур мәчет төзелеше тәмамлана. Моннан тыш 30лап фәнни форум, конференция, «түгәрәк өстәл», семинар, күргәзмә һәм бәйгеләр каралган. Кайбер чаралар әзерлек этабында, – диде вице-премьер.

Сүз уңаеннан, оештыру комитеты утырышына кадәр рәсми затлар 1100 еллыкка атап эшләнгән почта маркасына мөһер сугуда катнашты. Маркага Болгардагы Ак мәчет сурәте төшерелгән.

Башкарылган эшләр турында Татарстан Президенты да хисап тотты. Республика җитәкчесе сүзләренчә, Татарстанда дини мирасны саклау һәм популярлаштыру юнәлешендә зур эш алып барыла, мөселман илләре белән элемтәләр урнаша, булганнары ныгый.

Билгеле булганча, 1100 еллык кысасындагы чаралар Мәскәүдә дә узачак. Анда нәрсә көтеләсе хакында Россия мәдәният министры урынбасары Ольга Ярилова сөйләде. Федераль дәрәҗәдә барлыгы 70тән артык чара үткәрү ниятләнә. Төбәкләр дәрәҗәсендәгеләренең саны 1000нән артык.

Бергә булганда булдырабыз

Рәсми затлар бу көнне сүзгә дә, хискә дә саран булмады. Теләк-котлаулар мулдан ишетелде, хыяллар да яңгырады. Изге җир бит, чынга ашмый, фәрештәләр канат каккан мәлгә туры килми калмас.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов җыенга килүчеләргә рәхмәтен белдереп, бу тарихи вакыйганың әһәмиятен ассызыклады.

– 1100 еллык – республика өчен генә түгел, Россия һәм бөтен дөньядагы мөселманнар өчен дә мөһим вакыйга. Аның кысасында күп кенә чаралар узды, – диде ул. – Монда килгән һәммәгезгә рәхмәт. Сезнең безнең белән булуыгыз – шатлык. Ул изге урыныбыз – Болгарның имиджын күтәрә. Дөньяда тынычлык булсын, Татарстан чәчәк атсын, ә Россия көчле булсын.

Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев исә дистә еллар элек булган эшләр турында хатирәләргә тукталды. Дөресрәге, Болгарның ул чордагы халәтенә, башкарылган эшләргә.

– 2014 елда Болгар ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә керде. Дөньякүләм белгечләр Болгарның иң төньяк территорияләрдә ирекле рәвештә ислам динен кабул ителгән урыны булуын таныды. Без мөфти Тәлгать Таҗетдингә дә рәхмәтле! Ул – башлап йөрүче, мин моны гел әйтәм. Ул бездән алда килеп, кулына көрәк тотып, монда казу эшләрен башлый торган булды, – диде Дәүләт киңәшчесе.

Ахыры 4 нче биттә >

Шикәр һәм ашлык җитә

Татарстанда шикәр һәм ашлык яңа уңыш җыеп алганчы җитә. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, республикада 400 мең тоннадан артыграк бөртек запасы булдырылган. Барлык зур предприятиеләрнең җәй азагына кадәр ашлык белән тәэмин итүгә контрактлары бар. Республикага икмәк-күмәч кытлыгы янамый, зур сәүдә челтәрләре яңа уңыш җыеп алганчы продукция белән өзлексез тәэмин ителәчәк.

Шикәр дә җитәрлек күләмдә. Хәзерге вакытта шикәр заводларында 7 мең тоннадан артыграк әзер продукция саклана. Моның кадәр запас шикәр чөгендеренең яңа уңышын җыеп алганчы җитәчәк. Министрлыкта әйтүләренчә, шикәр заводлары складларында 7 мең тоннадан күбрәк шикәр саклана. Украинада махсус хәрби операция башлангач, продукциягә кытлык барлыкка килгән иде. Сәбәбе спекулянтлар һәм кайбер эшмәкәрләрнең намуссызлыгына бәйләп аңлатылды.

Егетләр армиягә китте

Татарстаннан 50дән артыграк егет хәрби хезмәткә китте. Язгы чакырылышта армия сафларына тәүге озату әле бу. Алар һава-десант һәм Росгвардия гаскәрләрендә хезмәт итәчәк. «Сез хәрби хезмәтне башлап җибәрәсез. Аны һәрбер ир-ат узарга тиеш. Безнең бурыч – Ватанны саклау. Хәрби-уку белгечлекләрен уңышлы үзләштерүегезне телим! Әйбәт хезмәт итегез!» – дип мөрәҗәгать итте булачак солдатларга республика хәрби комиссары Сергей Погодин.

Май – июль айларында республикадан 3 меңнән артыграк егетне армия сафларына җибәрү күздә тотыла.

«Каравон» юбилейга әзерләнә

Быел Татарстанда 30 нчы тапкыр «Каравон» бәйрәме үткәрелә. Ул шимбә, 28 май көнне узачак. Юбилей чарасында бик дәрәҗәле кунак – Пятницкий исемендәге Дәүләт рус академия халык хоры катнашачак. Лаеш районы хакимияте башлыгы Илдус Зарипов әйтүенчә, быел бәйрәмдә 170тән артыграк декоратив-гамәли сәнгать һәм кәсеп осталары, республикадан, төрле төбәкләрдән 170тән күбрәк иҗат коллективы катнашачак.

Узган елда «Каравон»да 8 мең кунак булып киткән. Быел ике тапкыр күбрәк – 15 меңләп кешене кабул итү күздә тотыла. Мәдәният министрының беренче урынбасары Юлия Әдһәмова әйтүенчә, ковидка бәйле чикләүләрне алу, бәйрәм күрергә теләүчеләрнең артуы туристлар санын ишәйтүгә ярдәм итәчәк. Быел районда моның өчен машина кую мәйданчыклары махсус каралган. «Кунакларның, бер килгәч, тагын киләсе килә, шулай итеп, мәйданчыклар, иҗат коллективлары саны елдан-ел артып, бәйрәм тагын да күркәмләнә», – дип билгеләп үткән Юлия Әдһәмова.

Яңа пособие алдылар

Татарстанда 8–17 яшькә кадәрге балалар тәрбияләүче 5 мең гаилә, шул исәптән 8,5 мең күпбалалы гаилә Россия Президенты кушуы буенча аз керемлеләр өчен билгеләнгән яңа пособие алган. Пенсия фондының Татарстан буенча бүлеге матбугат хезмәте хәбәренә караганда, аларга инде 625 миллион сумнан артыграк акча түләнгән. Кагыйдәләр буенча, яңа түләү алуга гариза 30 эш көне эчендә каралырга тиеш. Кабул ителгән карар турында хәбәр «Шәхси кабинет»ка җибәрелә. Гариза хупланганда, акча 5 эш көне эчендә мөрәҗәгать итүченең картасына килә.

Гаризаны Дәүләт хезмәтләре порталы, Пенсия фонды бүлеге һәм Күпфункцияле үзәк офислары аша тапшырырга мөмкин. Пособие гаиләдә җан башына туры килә торган керем 1 кешегә төбәктә билгеләнгән яшәү минимумыннан кимрәк булганда, ата-ананың мөлкәте таләптә билгеләнгәннән артып китмәгәндә, шулай ук кереме булганда (булмаса, моның нигезле сәбәбе кирәк) билгеләнә. Яңа түләү күләме ата-ананың кеременә бәйле. Ул Татарстанда бала өчен билгеләнгән яшәү минимумының 50, 75 яки 100 процентын тәшкил итәргә мөмкин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Көн үзәгендә

Җылы көтәбез

ЯҢГЫРЛЫ ҺӘМ САЛКЫН ҺАВА ТОРЫШЫНЫҢ УҢАЙ ҺӘМ ТИСКӘРЕ ЯКЛАРЫ

«Мондый салкын май булганын хәтерләмибез». Кем белән генә аралашсак та, әлеге сүзләрне кабатлый. Чыннан да, быелгы май гадәти булмаган суыклары, кыраулары һәм яңгырлары белән сыный. Явым-төшем аркасында кырларда эшләр тукталды. Районнарның яртысыннан күбрәгендә трактор гөрелтесе тынып торды.

Җитмәсә, синоптиклар да күңелне җылытырлык сүз әйтми. Авыл кешесенә, бакчачыларга нәрсәгә өметләнергә? Без салкын майның уңай һәм тискәре якларын барладык.

Чәчү ике атнага соңара

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат үзәге хәбәр иткәнчә, яңгырлы көннәрдә республика районнарының күпчелегендә язгы кыр эшләре туктап торган. Шунлыктан чәчү ике атнага соңарып бара, ди алар. Хәер, язгы кыр эшләре тоткарлануда явым-төшемне дә гаепләп булмый. Көнбагыш, шикәр чөгендере кебек җылы ярата торган культуралар да кояшлы, матур көннәрне көтә. Аграрийлар атна ахырына кадәр вазгыять үзгәрмәсә, алар урынына бөртекле культураларны чәчәргә туры килмәгәе, ди.

Хәер, эшләр барлык районнарда да бер төсле бара дисәк, дөреслеккә туры килеп бетмәс иде. Кайсыдыр районнарда кырга иртәрәк чыгып, күпчелек эшләрне башкарырга да өлгергәннәр. Мәсәлән, язгы культуралар чәчә торган мәйданнарның 80–85 процентында эшне тәмамлаучылар бар. Болар – Буа, Зәй, Мөслим, Спас һәм тагын берничә район. Шул ук вакытта язгы бодай, арпа һәм борчакны планлаштырган мәйданнарның яртысын гына иңләргә өлгерүчеләр дә бар. Лаеш, Саба, Питрәч, Кама Тамагы, Әгерҗе районнары – әнә шундыйлардан.

Чүпрәле районының «Агротранспорт» җәмгыяте агрономы Илдар Усманов әйтүенчә, майның яңгырлы булуы игеннәр өчен зыянлы түгел, тик дымы белән бергә җылы да булсын иде, ди ул.

– Узган ел без дә, туфрак та яңгырга тилмердек. Башта мескен җир яңгырны эчеп туя алмады. Эрегән кар суы, яуган һәр тамчы яңгыр җиргә сеңеп барды. 10, 12 майда көчле яңгырлар яуды. 1,5 атна эчендә 50 мм явым-төшем булып, айлык норманы тутырды. Шунысы яхшы: яңгырларга киткәнче, язгы культураларны чәчеп өлгердек. Бүген аларны тукландырабыз. Көзге культураларга корткычларга каршы гирбицидлар сибәбез. Гомумән алганда, бераз тоткарлыклар булса да, эшләр үз җае белән бара. Дөрес, көнбагыш – җылы ярата торган үсемлек, шуңа күрә аны әлегә чәчми торабыз.

Шулай да, агрономнар әйтүенчә, җылы булмауның уңай һәм тискәре яклары бар. Файдасына килгәндә, суык булгач, бөҗәкләр, корткычлар тиз генә уянмый.

– Башка елларда бу вакытларда агачлык тирәсендәге кырларда корткычларга каршы көчле көрәш бара иде инде. Быел – тынлык, – ди агроном.

Игенчелеккә зур начарлыгы булмаса да, яшелчәчелекнең башка тармаклары шактый сынала, ди Илдар Усманов.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Владимир ЖАВОРОНКОВ, Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары:

Бүгенге тынычлык ялган булырга мөмкин. Сәламәтлек саклау тармагында бернинди тынычлану да юк. Шуңа күрә халыкта да тынычлану була алмый. Роспотребнадзор коронавирусның көзгә кабат баш калкыту ихтималын кире какмый. Мондый хәлгә һәрвакыт әзер торырга кирәк.

(«Татар-информ»да узган матбугат очрашуында сөйләгәннәрдән)

РОССИЯДӘ – КОРОНАВИРУС

Узган тәүлектә илдә коронавирус белән авыруның 4158 очрагы ачыкланган. 5517 кеше савыккан, ә 775ен хастаханәгә салганнар.

ТӨБӘК	АЧЫКЛАНГАН	ХАСТАХАНӘГӘ САЛЫНГАН	САВЫККАН
Мәскәү	229	122	255
Санкт-Петербург	307	65	37
Свердловск өлкәсе	168	13	178
Татарстан	165	24	141
Волгоград өлкәсе	147	17	150
Саратов өлкәсе	140	3	149
Ростов өлкәсе	135	16	92

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ВАЛЮТАЛАР ТИШЕККӘ ОЧКАНДА

Хәтерлисезме: үткән елның көзендә, сентябрь аенда, без британ медиакомпаниясенә караган атналык The Economist журналы тышлыгында бирелгән валюталарның тишеккә очуын сурәтләгән рәсемне шәрехләгән идек.

24 сентябрьдә сайтта шул рәсемне үзебезнең дөньякүләм икътисад түнтәрелеше хакындагы язмага иллюстрация дә иттек. Ул язмада без: «Кәгазь һәм электрон акча чүплеккә очачак…» – дигән фаразны бер дә курыкмыйча бирдек. Икътисади һәм социаль системалар үлеменең төп бер билгесе бар: аларның валютасы тишек бер тиенгә дә тормый башлый, ягъни акча бар, аңа берни дә ала алмыйсың, алсаң да, гадәттән тыш кыйммәткә генә. Безнең сентябрь фаразы үзенең котылгысызлыгы белән тормышка ашу стадиясендә. Глобаль инфляция 40 еллык рекордны узып китте. Кичә долларга, еврога, юаньга җиңел генә сатып алган товарны бүген ала алмыйсың инде. Ышанычлы бер генә валюта да юк, малыңны акчага акча сатып алу юлы белән саклау хәзер мөмкин түгел. Глобаль реклама гипнозы ярдәмендә байрак итеп күтәрелгән криптовалюталар үзләренең кыйммәтләрен яшен тизлегендә югалта. Әле кичә генә безне «биткоин алмыйча оттырган мокытлар» дип атыйлар иде, бүген югары бәядән криптовалюта сатып алучылар канлы күз яшьләрен түгә.

Автор бу юлларны 22 май иртәсендә – «Биткоин – пицца көне» дип аталган истәлекле көндә яза. 2010 елның 22 маенда Ласло Хейниц исемле программачы бөек тарихи авантюраны башлап җибәрә: беренче тапкыр биткоин дип аталган виртуаль акчага товар – ике пицца сатып ала. Алар өчен ул ун мең биткоин сарыф итә. Менә шул көннән башлап биткоин бизгәге мәйданга чыга да инде, яңа акчаның кыйммәте ясалма рәвештә куык итеп кабартыла. Кем теләсә, шул баса ала торган криптовалюта кәгазь акча белән узышка чыга. Контрольдән тыш булу сәбәпле, бу акча мошенниклар, коррупционерлар өчен менә дигән җим ролен уйный башлый. Зур сәясәтчеләрне, дәүләт эшлекләрен сатып алу җиңелләшә, чөнки биткоин акча янчыкларына тикшерү органнарының теше үтми. Аңлашыла инде: криптовалюталарны популярлаштыру бөтен көченә бара, кайчандыр ике пицца алырга гына ярыган ун мең биткоинның бәясе берничә йөз миллион долларга җитә. Моннан унике ел элек ике пиццаны ун мең биткоинга саткан булсаң, син бүген инде мультимиллионер.

Гаҗәп түгел: җиңел баюның мондый ысулы массаларны кызыксындыра, шаукым тудыра. Бүген криптовалюталар кызу темплар белән үзләренең ясалма кыйммәтләрен югалталар. Моңа аптырарга кирәкми, чөнки берни белән дә тәэмин ителмәгән, кемнәр тарафыннандыр язып кына куелган саннар хакында сүз бара. Менә бу кәгазь битенә мин бер тәңкә дигән язу язып, аның кыйммәтенә башкаларны ышандыра алсам, шулай ук миллионерга әйләнер идем. Европа Үзәк банкы президенты Кристин Лагард әле яңа гына тагын бер тапкыр: «Криптовалюталар бернигә дә нигезләнмәгән», – дигән белдерү ясады. Аларның бәя үсеше – чегәннәрне көнләштерерлек гипноз нәтиҗәсе генә ул. Массалар гипноздан айный башлау белән ялган кыйммәтләр мизгел эчендә юкка чыга. Иң күп биткоин тотучы MicroStrategy (аның балансында 3,5 миллиард долларлык 115000 BTCтан артык акча бар) биткоинның бәясе 11 мең доллардан да түбәнгәрәк җимерелергә мөмкинлеген белдерде. Ethereum дип аталган криптовалюта уйлап тапкан Виталий Бутерин иң яшь миллиардер булудан туктады. Аның бәясе 3000 долларга җиткән криптовалютасы бүген 1963 доллар гына йөри. Дөресен генә әйткәндә, урланган акчасын яшерергә теләгән зур түрәләр күп булмаса, Ethereum тишек бер тиенгә дә бәяләнмәс иде.

Россиядә

НИШЛӘТӘСЕҢ БЕЗНЕ, ДОЛЛАР?

Россиянең финанс базарында гаҗәп хәлләр криптобиржалардагыдан бер дә ким түгел. Әле кайчан гына мал саклауның иң ышанычлы ысулы булып саналган доллар һәм евро сатып алу үзенең тәэсирле куәтен югалтты.

Резерв валюталарының биржа бәясе һәм рәсми курсы баш әйләндерерлек дәрәҗәдә түбәнгә тәгәри. Доллар илле сумга калып бара, евро да шуның артыннан иярә. Бу юллар язылганда, «Ак барс» банкның Арча бүлекчәсе долларны 58 сумнан сатып ала иде. Дөрес, сиңа сатканда рәсми курстан күпкә югарырак сата инде ул аны, 65 сум 53 тиеннән бирәбез, диделәр. Әмма, килешәсездер, 2022 ел өчен соңгы сан да бик түбән. Без бит инде долларны 200 сумнан да түбәнгәрәк алудан өмет өзгән идек.

Без кәгазь акчаның чүпкә әйләнүенең классик мисалының шаһитларына әвереләдек. Ирекле рәвештә үзең теләгән товарны теләгән күләмдә сатып ала алмыйсың икән, доллар да кәнфит кәгазеннән берни белән дә аерылмаячак. Без моны соңгы совет чорында сум белән бәйле рәвештә бер күзәткән идек. Хезмәт хакы аласың, әмма аңа берни дә сатып алып булмый диярлек. Чынлыкта бушка эшләдек инде без ул елларда. 1991 елда айлык хезмәт хакына бераздан соң бер ипи дә тимәслек булды. Андый шартларда беркемнең дә эшлисе дә, сәүдә итәсе дә килми. Икътисад җимерелә. Вазгыять доллар белән янә бер тапкыр кабатлана.

Әйе, Россия, кыйбат бәядән углеводородлар сатып, гаҗәп зур табыш ала. Әмма ни шатлык?! Ул табышка безгә товар бирмиләр. Асылда без углеводородларны бушка озатабыз булып чыга. Көнбатышлыларга бездәге банк хисапларына фәләнчә миллиард доллар дигән сан язып куюның бер кыенлыгы да юк бит. Алар бездән кыйммәтле чимал алалар һәм алмашка берни дә бирмиләр, хәтта кәгазь долларлар кертү дә санкция белән тыелды. Хәтта Кытай да безгә товарларын бик үлчәп кенә бирә. Россия – Кытай сәүдә әйләнеше зур темплар белән үсә үсүен, әмма без сатабыз, Кытай ала рәвешендә генә. Җитмәсә, чиннар бездән чималны бик зур дисконт белән, ягъни дөнья базарындагыдан күпкә арзанрак бәядән алалар. Кытайдан Россиягә апрель импорты 26 процентка кимегән, мәсәлән. Мартта Россиядән Евросоюзга экспорт 75 процентка үскән, ә импорт 55 процентка түбәнәйгән. Чит илләр бездән реаль товар алалар да доллар-евро дигән сан саталар. Белгечләр хәзер чаң суга башлады инде: доллар курсының үсеше ил икътисадына файдага түгел, диләр. Хәзер инде: «Сумның курсы ныгу – Көнбатышның безгә ясаган яшерен һөҗүме», – дип әйтүчеләр дә бар. Доллар дөнья масштабында мәтәлчек атып, бернигә дә ярамаган кәгазьгә әйләнсә, чимал сатып җыйган йөзләгән миллиард долларлык резервларыбыз чүпкә калачак. Процесс акрын гына шул юнәлештә бара.

ТОРМЫШ ДӘРЕСЛӘРЕ

Китапта – тарих

Фәрит Мөхәммәтшин парламент рәисе булып эшләгән чорда 3 меңгә якын закон кабул ителгән. Ул, Җир шарын утыз тапкыр әйләнеп, гомеренең 1200 көнен командировкада уздырган. Бу саннар Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның 75 яшьлек юбилеена багышланган «Фарид Мухаметшин. Виражи судьбы» китабын тәкъдим итү кичәсендә яңгырады. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов аңа «Дуслык» ордены тапшырды.

tatarstan.ru

Милли китапханәнең фойесында Фәрит Мөхәммәтшинның төрле еллардагы эшчәнлегенә багышлап, фотокүргәзмә оештырылган иде. Монда аның балык тоткан, волейбол уйнаган, ретро машиналар янында кайнашкан фотолары да урын алган. Чарага килүче кайсы депутаттан гына сорасаң да, аны зирәк сәясәтче, көчле җитәкче, ышанычлы дус, кайгыртучан гаилә башлыгы дип бәяләде. Истәлекләргә бай булган, җылы бер кичә булды бу. Лаеклы җитәкче турында башкача сөйләп тә булмыйдыр.

– Без Фәрит Хәйруллович белән ул сәнәгать министры булып эшләгән еллардан ук таныш. Шушы еллар эчендә аның белән бер тапкыр да ачуланышканыбыз булмады. Бу – икебезнең дә яхшы сыйфатыдыр. Үзебезнең түгел, республика мәнфәгатьләрен кайгыртабыз. Фәрит Мөхәммәтшин белән төрле өлкәләрдә кулга-кул тотынышып эшләдек. Бернинди аңлашылмаучанлык та юк – Президент Аппараты, Хөкүмәт… бурычлар куелган һәм барлык мәсьәләләр хәл ителә. Бездә – ышанычлы парламент, бу – җитди эш. Башкарма хакимият ышанычлы парламентсыз була алмый, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент Фәрит Мөхәммәтшинның Татарстан Халыклары Ассамблеясы юнәлешендә дә зур эшләр башкаруын билгеләп үтте. Аңа уртак эш өчен рәхмәтен җиткереп: «Тормыш иптәшегез Луиза Әкърәмовна гел янәшәгездә булсын, балалар, оныкларыгыз белән тигез гомер кичерегез. Республикада да, илдә дә тотрыклылык булсын», – дип теләде.

Татарстан Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев китапны югары бәяләде. «Сезнең турында язу җиңел түгел, әмма ул яхшы язылган», – диде Минтимер Шәймиев. Фәрит Мөхәммәтшинны бик тыйнак кеше дип атады. Иң авыр елларда аның Татарстан Югары Советын җитәкләвен искә төшерде. «Аның слесарьдан партия юлбашчысына кадәр күтәрелеп, катлаулы юл үтүен бик сирәкләр беләдер», – диде Беренче Президент.

Аны ТАССР сәүдә министры вазыйфасына ул үзе чакырган. Дәүләт киңәшчесе әйтүенчә, Фәрит Мөхәммәтшинның 1970 нче еллар башыннан Әлмәттә партия, хуҗалык һәм сәяси вазыйфаларда эшләве күп нәрсә турында сөйли. Ул вакытта нефть төбәге Россиядә әйдәп баручыларның берсе булган. «Бу күп кенә товарларга кытлык кичергән чак иде. Әлеге вазыйфаны башкаручы тәртипле, ышанычлы кеше булырга тиеш. Без Фәрит Хәйрулловичны сайлап алдык», – диде Минтимер Шәймиев.

Узган гасырның туксанынчы елларында Фәрит Мөхәммәтшин Татарстан Югары Советын җитәкли башлый. Республика суверенитет игълан иткәннән соңгы елларны Минтимер Шәймиев сәяси көрәшнең чын сәхнәсенә тиңләде. Ул билгеләп үткәнчә, республика бик катлаулы юл узды. «Аллага шөкер, бүгенгә кадәр республика хакимиятнең барлык дәрәҗәләрендә дә килешеп эшли», – диде Дәүләт киңәшчесе.

Башкортстан Дәүләт Җыены Корылтай рәисе Константин Толкачев Фәрит Мөхәммәтшинны «Салават Юлаев» ордены белән бүләкләде.

– Татарстан һәм Башкортстан кебек ике дус парламент тагын бармы икән? Без күп темалар буенча фикерләшеп, киңәшләшеп эшлибез, – диде Константин Толкачев.

Федераль депутатлар да юбиляр турында үз фикерләрен җиткерде. Россия Дәүләт Думасы депутаты Олег Морозов башта Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володинның котлавын укыды. Аннан үзенең теләкләрен җиткерде. Аны зирәк, көчле сәясәтче дип бәяләп, гомер буе аннан өйрәнүен әйтте.

Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенко видеоэлемтә аша Фәрит Мөхәммәтшин турында: «Сезнең абруегыз төбәкләр арасында гына түгел, федераль халык сайлаучылары арасында да югары. Дәүләт эшлеклесе буларак, сезне хөрмәт итәләр. Бу бигрәк тә закон чыгаручылар советында уртак эшебездә сизелә. Сезнең фикерегезгә, киңәшләргә колак салалар, чөнки тәкъдимнәр Россиянең иң уңышлы төбәкләренең берсе вәкиленнән килә. Сез танылган лидер гына түгел, искиткеч команда уенчысы да», – диде.

Фәрит Мөхәммәтшин, катлаулы елларда Югары Советны җитәкләвемә бер дә үкенмим, диде. Шулай ук үзенең татарчаны өйрәнүе турында да сөйләде. Хәер, бу хакта аннан беренче мәртәбә генә ишетмибез. Әмма күпме генә тыңласаң да, үзе бер дәрес!

– Берсендә Фәүзия Бәйрәмова утырышны ике дәүләт телендә алып баруны тавышка куюны сорады. Сүз байлыгым юк, хәзер хупласалар, сәяси бәхәскә, сөйләшүгә кереп китәсе булса, ничек сөйләшермен, дип борчылдым. Шунда үземә туган телемне өйрәнергә сүз бирдем. Көзге каршына утырып, Разил Вәлиев, Туфан Миңнуллин китапларын кычкырып укый, аңламаган сүзләрне Туфан Миңнуллиннан сорый идем. Тормыш мине гомер буе укырга мәҗбүр итте, – диде ул.

Китапны тәкъдим итү кичәсенә Фәрит Мөхәммәтшинның гаиләсе – хатыны Луиза Әкърәмовна, улы-килене, кызы-кияве дә килгән иде. Ахырдан парламент башлыгы аларга да рәхмәт әйтте. «Луиза, сиңа – сабырлыгың, балалар, сезгә йөземә кызыллык китермәвегез өчен рәхмәт… Без – бәхетле кешеләр», – диде ул.

Сәрия МИФТАХОВА

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Татарстан Арбитраж суды – эшмәкәрләрнең, юридик затлар һәм дәүләтнең хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен яклаучы ышанычлы гарант. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Арбитраж суды оештырылуга 30 ел тулуга багышланган чарада шулай дип белдерде.

Рөстәм Миңнеханов басым ясап әйткәнчә, Татарстан – икътисади яктан көчле төбәк. Бездә бизнес алып бару өчен кирәкле барлык шартлар тудырылган. «Арбитраж суды икътисади тормышта законлылыкны ныгытуга, эшмәкәрләрнең хокукый аңын, «сәламәт» көндәшлек мохитен булдыруга, Татарстанның инвестицияләр җәлеп итү өчен уңай төбәк булып торуына гаять зур өлеш кертеп килә», – диде Президент.

Аның әйтүенчә, судьялар һәм суд аппараты хезмәткәрләренең компетентлыгы суд бәхәсләрен закон буенча, гадел төстә хәл кылуның нигезе булып тора. «Гаять зур тәҗрибәгә ия булуы республика Арбитраж судына зур абруй-хөрмәт китерде. Суд ветераннары моңа бик зур өлеш кертте: алар Татарстанда Арбитраж судын нәтиҗәле үстерүгә нигез салды. Без аларга моның өчен эчкерсез рәхмәтлебез», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент Арбитраж судының көчле судьяларга, бөтен барлыгын биреп эшләүче бердәм коллективка ия булуын аерым билгеләп үтте. «30 ел эчендә күп эшләнде. Әмма алда әле яңа бурычлар тора. Югары дәрәҗәдәге профессионализмга ия булуыгызның аларны уңышлы хәл кылуга ярдәм итәсенә ышанам. Сезгә нык сәламәтлек, тынычлык һәм иминлек, Татарстан, Россия файдасына эшчәнлегегездә уңышлар телим!» – дип мөрәҗәгать итте залга җыелган халыкка Рөстәм Миңнеханов.

Соңыннан ул «иң-иң»нәргә Татарстанның дәүләт бүләкләрен тапшырды.

***

Сьерра-Леоне Республикасының Россиядәге Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле Илчесе Мөхәммәд Йонгаво белән Хөкүмәт йортында узган очрашуда Президент Рөстәм Миңнеханов бу ил белән хезмәттәшлекне үстерү турында фикер алышты. «Африка безнең өчен – уникаль төбәк. Россиянең Африка илләре белән мөнәсәбәтләре һәрвакыт җылы булып калды һәм конструктив рәвештә үсеш алды», – диде ул.

***

Казанда «Радиоэлектрон технологияләр концерны» АҖ генераль директоры Александр Пан белән очрашуда әлеге концерн составына кергән һәм Татарстанда урнашкан предприятиеләрнең эшчәнлеге, җитештерүне яңарту, ике арадагы хезмәттәшлек турында фикер алыштылар. Татарстанда «КРЭТ» составына 4 предприятие – «Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ, «Радиоприбор» АҖ, Әлмәт «Радиоприбор» заводы» АҖ һәм «Рычаг» АҖ керә.

ҖЫЛЫ КӨТӘБЕЗ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Хуҗалыкта бәрәңге, суганнар да утырттык, чөгендер дә чәчтек. Җирдә бу культураларга куркыныч тудырырлык суык юк. Безнең хуҗалык зелпе, җиләк тә үстерә әле. Былтыр бу чорда зелпенең беренче уңышын җыя башлаган идек инде. Ә быел әле чәчәктә генә утыра. Җиләк әлегә бөтенләй чәчәккә дә бөреләнә алмый. Аларга җылы кирәк, әлбәттә. Башка культураларга да җылы булу яхшы, тик көннәрнең кинәт югары градуска күтәрелүе шулай ук куркыныч. Чөнки юешрәк җирләрне катырып, ярып җибәрергә мөмкин. Җиләк ашамыйча да торып була, ә менә икмәксез бер нишләп тә булмый, – ди белгеч.

«Яшелчәләрне бернигә дә карамыйча утыртыгыз»

Быелгы салкын һава торышы игенчеләрне генә түгел, бакчачыларны да аптырашта калдырды. Узган елларда бу чорга утыртасы утыртылган, чәчәсе чәчелгән, кыскасы, бакчаларда бер кат эш беткән була торган иде бит. Быел исә күпчелек халык, җир салкын дип, «икенче икмәк»не җиргә тапшырырга куркып тора. Май башындагы берничә җылы көндә эшләрен бетергән кешеләрнең дә тынычлыгы бетте. Алар: «Җир астында бәрәңге череп ятмый микән, тишелеп чыга алырмы икән?» – дип борчыла.

– Утырткан кешеләргә борчылырлык бер сәбәп тә күрмим. Ә калганнар, помидор, кыяр һәм кабактан кала, барлык яшелчәләрне бернигә дә карамыйча утыртсыннар. Алар салкын тия торган культуралар түгел, – дип киңәш бирә андыйларга Арча районының Ашытбаш авылында яшәүче оста бакчачы, «халык синоптигы» Рәис Шәкүров. – Майда мондый суыклар 100 елга бер тапкыр булгандыр. Алга таба көннәр барыбер җылытуга таба барачак. Май башларында җиргә кереп урнашкан бәрәңге, киресенчә, көчле булып чыгачак, чөнки тамырлары нык, көчле. Көн суык булу аркасында өскә тишелеп чыкмаса да, тамырларын көчәйтә ул. Кояш чыгып, җылытуга таба киткәч, яхшы итеп үсеп китәчәк.

Бакчачы әйтүенчә, җир инде җылынган. Аның өлгерүен ул туфрак өстендәге кызыл беткә чамалап билгеле икән. Рәис абый үзе инде бакчадагы күпчелек эшләрне төгәлләгән. Бәрәңге, кишер, кәбестә һәм чөгендер – барысы да туфракка кереп урнашкан.

Алмагачлар чәчәк ата майның унбишләрендә, дип тә җырлап булмады быел. Күпчелек районнарда алмагач, шомырт агачлары да чәчәк ата алмыйча азаплана. Рәис Шәкүров сүзләренә карасак, аның шулай булуы хәерлерәк тә икән.

– Арча якларында алмагачлар чәчәккә бөреләнгән генә әле. Әгәр шушындый салкында җимеш агачлары чәчәк ата икән, алма да, чия да булмаячак. Бу салкыннарның агачларга да зыяны күп булды. Усак, каен агачларының яфраклары саргаеп утыра: яшь бөрене салкыннар алды, – ди ул.

Суыкларның хәтта карга, умарта кортларына да йогынтысы зур.

– Каргалар бала чыгара алмады быел, – ди Рәис Шәкүров. – Йомыркаларына салкын тиде, үзләре ояда утыра-утыра ябыгып беттеләр. Шуңа күрә быел кошлар азаячак. Кешеләр каргаларны яратмасалар да, аларның файдасы бар. Чәчелгән культураларның тамырларын ашаучы корткычларны юк итә бит алар. Ә балалары булмагач, ризык ягын кайгыртмаячаклар. Икенче яктан, суыклар булгач, кайбер корткычлар да кимеячәк. Бал да аз булачак быел. Чөнки безгә түгел, үзләре өчен дә бал җыя алмыйлар. Әйе, җылы кирәк. Җирдә хәзер дым бар, инде җылы көтәбез.

Халык синоптигы Рәис абыйның фаразлавы буенча, көннәр 28 майга җылыта башлаячак.

– Мин алдан ук, май да, җәй дә салкын була, дип кисәттем, – ди ул. – Җәй, давыллар, гарасатлар, яшенле яңгырлары белән куркыныч. Әгәр кыш белән тәңгәлләштереп карасак, июньдә дә, июльдә дә шундый әшәке, көчле җилле көннәр булачак. Эссе җәйгә өметләнмәгез быел.

КФУның метеорология кафедрасы мөдире Юрий Переведенцев исә, Татарстанда 30 майга кадәр һава температурасы нормадан 5 градуска түбән булачак, ди.

– Сишәмбе кырау һәм минус 1 градуска кадәр салкын булачак. Чәршәмбе дә җылы көтмәгез. Мондый аномаль салкын һава торышы, мондый салкын һәм яңгырлы май 74 ел булмады. Хәзер температура климатик нормадан 6–7 градуска түбәнрәк. Ул бүген 15 градус булырга тиеш. Хәзер безнең климат буенча инде җәй башланырга тиеш, – диде Юрий Переведенцев.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Фоат Гарифуллин

«ИРДӘҮКӘ» БӘХЕТЕ НӘРСӘДӘ?

Премьера

Туган көненә тамашачыга бүләк. Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев әнә шулай эшләде. Сәхнәне юбилей котлауларыннан, тантаналы сүзләрдән азат итеп, премьера күрсәтте. Дөресрәге, көз көне булачак премьераның репетициясенә дусларын, тамашачысын җыйды.

Зал, балконнар шыгрым тулы иде. Бер караганда, татар театры дөньясындагы беренче номерлы режиссерның бәйрәме шулкадәр халык җыярга тиештер дә. Әмма биредә тагын бер сәбәп бар: татар халкының җитди әсәре – «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» дилогиясе сәхнәгә менә. Фәрит Бикчәнтәев аны үзе дә «ВТ» белән әңгәмәдә татарның энциклопедиясе дип атаган иде:

– Җирдә татар яшәгән вакытта бу әсәр, андагы вакыйгалар, фаҗига актуаль булачак. Мондагы һәрбер күренешнең нигезендә фаҗига ята. Халкыбызның фаҗигале авыр тормышы. Спектакльдә «бәхет» сүзе кабатлана. Аерым кеше өчен нәрсә ул бәхет? Халык өчен бәхет нәрсәдә? Кайда ул? Кайсы илдә? Кешене бәхетле итәрлек ил, гомумән, бармы? Нишләп кайберәүләргә бу илдә дә, чит җирдә дә бәхетле булырга язмаган? Әнә шундый сораулар куябыз, җавабын исә тамашачы үзе табар.

Спектакль XIX гасыр башындагы бер авыл, аның яшәешен сурәтләү белән башлана. Аулак өй, авыл җыены, кичке уеннар, кызларның киндер тукуы һәм башка әнә шундый күренешләр пластик күренешләр белән дә аңлатыла. Авыл тыныч яши, тик иреклеме ул? Бу сорау авылны камап алган күзәтү каланчалары, андагы яктырткычларны күргәннән соң туа. Халык гел күзәтү астында. Аннан ачлык килә, алда тагын сынаулар көтә.

Спектакль халык язмышын тулаем ача алганмы соң? Әдәбият белгече Миләүшә Хәбетдинова әлегә сорауларга җавап табылмады дигән фикердә:

– Камал театрының Мәхмүт Галәү әсәренә алынуы сөендерде. Чөнки анда «Ни өчен татар дөнья буенча сибелгән?» дигән сораугa җавап бар. Әмма спектакльдә бу сорауга җавап ишетелмәде. Режиссер гади бер гаилә тарихына мөрәҗәгать итә һәм бәхет турында уйланганда хатын-кыз роленә басым ясый. Ир кеше бу спектакльдә югалып калган, төп карарларны хатын-кыз кабул итә. Әлеге фикер берничә гаилә мисалында раслана. Татар тормышына карасаң, XIX гасырда аны кузгаткан төп сәбәп ачлык түгел, төп сәбәп – халыкны исәпкә алу, ә бу вакыйга күрсәтелми. Мәсәлән, Каюм Насыйри белән очрашу күренеше юк, җәмгыять катламнарының бер-берсе белән бәйләнеше күрсәтелмәгән. Без фәкать Төркиягә бәхет эзләп чыгып киткән һәм картайгач кире кайткан мөһаҗирне, аның авыл диванасы белән сөйләшеп йөрүен күрдек. Хатирәләр клип сыман бер-бер артлы бирелә, алар арасында бәйләнеш юк. Гәрчә режиссер Фәрит Бикчәнтәев, «Килмешәк» спектаклен чыгарганда, авторда булмаган идеяләрне кертеп, татар гаиләсен тудырган, нечкә детальләр белән баеткан иде. Сүз уңаеннан, «Ирдәүкә»дә Илгиз Зәйни куелышындагы «Адәмнәр» спектакле белән уртаклык бар. Икесендә дә беренче урында – ачлык темасы, әмма механизмнары ачылмаган. «Халыкның ачлыктан кырылуында кем гаепле?» дигән сорауга, татар үзе гаепле, дигән җавап бирелә. Ак патша гаепле түгел, җирле хакимият, дин әһелләре гаепле килеп чыга. Без һаман гаепне татарның үзеннән эзлибез. Минем «Ни өчен татар сибелгән?», «Нигә без туган җирдә күмәкләшеп яшәмибез?» дигән сорауларга җавап ишетәсем килә. Академик театр исә татар тарихын гадиләштерергә тиеш түгел.

Театр тәнкыйтьчесе Нияз Игъламов исә спектакльгә бәя бирергә иртә дип саный:

– Әлегә анализ ясарга иртә. Чөнки без өч өлештән торган киң полотнолы әсәрнең бер бүлеген генә күрдек. Тулаем карагач, бәя бирербез. Сафа белән Газиз ага диалогында зур мәгънә ята, минемчә. Аннан соң, хатирәләргә корылгач, ул реалистик әсәр була алмый. Мистик алымнар белән куелган. Әлегә режиссер безне әзерли генә. Мин хәтта өч бүлек кенә булмаячак дип уйлыйм. Бу – ике кичәдә уйнала торган спектакль. Бәлки кайбер моментлар кыскартылыр, бәлки нәрсәләрдер өстәлер. Бу дилогияне укыган һәр кешенең үз фикере. Режиссер Ренат Әюпов, мәсәлән, Минзәлә театрында «Мөһаҗирләр»не куйды, әмма «Болганчык еллар»га бөтенләй тотынмады. Фәрит Бикчәнтәев төп сәбәпләрне күрсәтергә омтыла. Авыл өстеннән зонадагы кебек каланчалар урнашуы һәм аларны кара киемле кешеләрнең яктырткычлар белән яктыртып торуы – шуңа ишарә. Андый метафоралар шактый булды. Әмма әлегә анализ ясап булмый, ярамый да. Тулаем спектакльне көтик.

Россия кинематографчыларының Татарстан бүлеге рәисе, режиссер Илдар Ягъфәров әйтүенчә, бу – Фәрит Бикчәнтәев иҗатының яңа этабы башлануын күрсәтә торган әсәр:

– Спектакльгә куркып кына бардым. Катлаулы әсәр бит. Фәрит өчен бигрәк тә әһәмиятле әсәр. Миңа калса, ул үзгәрү юлында. Мәхмүт Галәү әсәренә бөтен кеше алынырга тели, шул ук вакытта аңа алынырга куркалар да. Фәрит, миңа калса, куелган бурычларны үтәп чыга алган. Нәтиҗәдә кинематографик элементларга бай спектакль килеп чыккан. Композициясе бик матур, заманча. Әйтергә кирәк, әле бу юлның башы гына. Шунысы да бар: күп кешеләр «Мөһаҗирләр» әсәре белән таныш. Ә менә «Болганчык еллар»ны бик аз кеше укыган. Халык исәбен алуга кадәрге авыл, кешеләр, аларның тормышы, үзара мөнәсәбәте – без менә шуларны күрдек. Төп мәсьәлә – халык исәбен алу, авыл агайларының котылу юлын мөһаҗирлектә күрүе икенче, өченче кисәкләрдә булыр, миңа калса. Фәрит шуңа әзерләнә дип уйлыйм. Актерларның бер урында таптанып тормавы, эзләнүе бик ошады. Татарстанның халык артисты Радик Бариев (Газиз ага), Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Люция Хәмитова (Патый-Фатыйма) бөтенләй башкача ачылды. Әлбәттә, мин белгеч түгел, тамашачы буларак фикеремне әйтәм: кайвакыт Камал театрында күренешләр (мезансцена) барып чыкмый иде. Ә монда актерларның һәрберсе куелган бурычын белә һәм образларны бөтен нечкәлекләре белән бирә. Бәхетле язмышлы әсәр булыр дип ышанам. Бәлки әле «Зәңгәр шәл» язмышын кабатлар.

Язучы Рабит Батулла, спектакль беренче карашка вак, чынбарлыкта бик зур мәсьәләләрне күтәрүе белән дә әһәмиятле, дигән фикердә:

– Спектакль куелышы, җиһазланышы, мәсьәләләрнең чишелеше ягыннан да оригиналь. Зур мәсьәләләр күтәрелүе белән әһәмиятле. Мәсәлән, Саҗидәнең иренә икенче хатын сайлавы. Әдәбиятта бу тема күтәрелгәне бар. Мәхмүт Галәүдә Саҗидә, ирен яратканга, аны балалы итәргә омтыла. Бу – хәзер дә аңлашылып бетмәгән, татарларга гына хас булган күренеш. Ике хатынның бер арбага җигелеп тартып китүе белән шаккатырды. Алга таба ни булыр, күрербез инде. Сәхнәдә мөһаҗирлектән туган авылына кайтып егылган карт Сафаның даими күренүе дә – алга таба җитди сораулар куелачагына ишарә.

«Ирдәүкә» бу сезонда башка күрсәтелмәячәк. Тулысынча аны ноябрьдә, режиссер Марсель Сәлимҗановның туган көнендә күрү мөмкин булачак. Күрелгән кадәресе дә төрле фикерләр уятты. Әмма беркемне дә битараф калдырмады.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

58 яшьтә дә курчак уйный

Юмарт Нурфия дип йөртәләр аны авылда. Үзенә калмаса калмый, соңгы әйберен дә кешегә биреп җибәрә ул. Теккәнен өләшә тора. Әле бит акчага түгел, бушлай!

Зөлфия Хәлиуллина

Зәй районының Аксар авылында яшәүче Нурфия Хөснетдинова безне: «Бөтен курчакларым, кул эшләремне күргәзмәгә биреп җибәргән идем шул, күрсәтергә матур әйберләрем дә юк», – дип уңайсызланып кына каршы алды. Шуңа күрә күбесен фотодан гына карарга туры килде. Курчаклары арасында төрле милләт кызлары да, пешекчеләр, табиблар һәм башка һөнәр ияләре дә бар.

Нурфия апа 36 ел буе мәктәптә башлангыч сыйныф укучыларын укыткан. Үзе дә шушы авылныкы. Укытып кына калмаган, кул эшләре түгәрәген дә алып барган. Кызларны чигәргә, тегәргә, бәйләргә, пешерергә өйрәткән. Казанда «Гаилә дәресләре» курсын тәмамлауның да файдасы тигән. Нурфия апаларының мәктәбен үткән кызлар гаиләдә дә уңган хуҗабикәләрдер, шәт. Үз өен дә үзе киендергән. Кибетнекенә кызыкмый. Пәрдәләрен дә теккән, юрганнарын да ясаган. Бер әйберне дә кешегә эшләтергә яратмыйм, ди.

– Мин – әйберләргә икенче сулыш өрүче. Без үскәндә, бер әйбер дә юк иде. Гаиләдә өч кыз идек. Апалардан калган киемнәрне кияргә туры килде. Әнинең алъяпкыч теккәнен көтеп утыра идем. Ул тиз генә тегеп бетерә дә калган тукымадан мин курчакларны киендерәм. Бер әйберне дә әрәм итмим. Өр-яңа яулыклар, тукымалар тик ята бит. Модасы чыкса да, берни булмаган. Шулардан баш киемнәре ясыйм. Бер теккәндә 12шәрне тегәм. Яулык урынына менә дигән башлык килеп чыга. Авылдагы хатыннарны да бу шөгыльгә өйрәттем, алар да остарып бетте инде. Киелгән кофталар башмаклар ясарга ярый, – ди Нурфия ханым.

Иске әйберләрне заманчалаштырырга да ярата. Шәлләрдән сумкалар теккән, бизәнгеч, акча янчыклары, муенсалар… – барысы да аның иҗат җимешләре. Мунчала да бәйли. Оныклары өчен дә әллә ниләр уйлап таба. Кечкенә курчакларны зур итеп үзгәртә.

– 58 яшьтә дә курчак уйнаудан туктамадым әле мин. Ташланган, кулы чыккан курчакларга кабат җан өрәм. Кирәкмәгәннәрен өйгә китереп бирүчеләр дә бар. Кечкенәләрен пластмасса шешәгә куеп зурайтам. Балалар килгәч, уйнарга сорыйлар. Оныкларга бүләк итеп биреп җибәрәм, – ди тегүче. Әмма ул үзен тегүче дип санамый. Искене яңартучы мин дигән сүз белән күбрәк килешә.

Лаеклы елга чыккач та, ике елдан артык мәктәптә эшләгән әле ул. Өйдә ял итү рәхәт икән, дип куя. Үзе дә ут борчасыннан ким түгел. Шул арада безгә башмак өлгеләрен дә сызып күрсәтте, шкафында күптән бәйләнгән шәлләрен дә тартып чыгарды. Тәрәзә төбендәге гөлләре турында гәпләшеп алдык. Әйтерсең, хезмәт дәресендә булдык.

– Бүген көн яңгырлы була дигәч, бәйләү бәйләрмен дигән идем. Хәзер берәр башмак башлармын. Бер генә минут та тик торырга яратмыйм. Бүләк иткән әйберләремнең кемгәдер файдасы тисә, сөенәм. Яңа идеяләр туа. Тегү машинасын буш тотмыйм, кыскасы, – ди ул.

Укытучы укытучы инде. Энергиясе ташып, булган белемен кешегә өләшеп торасы килә аның. Безне озатканда, Нурфия ханым ишегалдында бик мәгънәле шигырь дә сөйләп күрсәтте. Тормышның агына да, карасына да шөкер итә белү турында иде ул. Яңгыр ява башлады. Димәк, Нурфия апа кул эшенә тотыныр, тагын башкаларны сөендерүен дәвам итәр.

Сәрия МИФТАХОВА

КАДЕРЛЕ КЕЛӘТ

Балтач районының Кариле авылында яшәүче Сәрия апа Сафина алты ел элек өендә музей ачкан. Келәт алдына 60ка якын экспонат җыйган. Алар арасында күмер үтүкләре, куыклы лампа, самавыр, табагач, кисәү агачы – ниләр генә юк! Әти-әниләре, әби-бабайларының көнкүрештә кулланган әйберләрен кадерле ядкарь итеп саклый ул.

Берсен дә чүпкә чыгарып атмадым. Моңа минем кулым да бармас иде. Келәт алдына утырып, хатирәләрне искә төшерүгә ни җитә! Үткәннәрне онытырга ярамый, – ди Сәрия Сафина.

Сәрия апа укытучы да, тарихчы да түгел. Озак еллар хисапчы булып эшләгән. Ә музей «уфалла» арбасының ватык тәгәрмәченнән башланган. Ире Габделнур абый: «Хатын, моны ташларга җыеналар, сиңа кирәге чыкмасмы?» – дип, күршесеннән күтәреп чыккан. «Шәп иткәнсең, иртәгә нәрсә эшләп булганын күрсәтермен», – дигән ул. Икенче көнне ире эштән кайтышка яхшылап буяп, келәт алдындагы кадакка элеп куйган. Моңа кадәр Сәрия апа элеккеге көнкүреш кирәк-яракларын, ягъни бал тәпәнен, җир эшкәртә торган кәйлә, кисәү агачын, үлчәвен капчыкка, сандыкка җыеп барган.

– Келәт алды – бик җайлы урын ул. Яңгыр да, кар да керми. Анда башта олы оныгыбыз уйнап үсте, хәзер башкалары да шунда мәш килә. Теге тәгәрмәчне элеп куйгач, башта уйлар бөтерелә башлады. Нигә әле керосин лампаларын, үзем чутлаган счетларны, самавырларны да шунда куймаска? Төп нигезем – Норма авылында. Безнең авылларны бары олы юл гына аера. Андагы әйберләрне дә, килен булып төшкән өйдәге вак-төякләрне юып, чистартып шунда урнаштырдым. Еллар буе тузан җыеп яткан кисәү агачы, соскыч һәм башкаларга да урын табылды. Күсе елында тугангамы, бөтен нәрсәне дә җыям мин. Әнинең Яңгулда яшәүче апасы Сәядәдән дә керосин лампасы, самавыр, ипи калагы, бал кисмәге алып кайттык. Музейдагы әйберләр шушы өч гаиләнеке. Бүтән кешедән алмадык, – ди музей мөдире.

Йомыш белән керүчеләр арасында, нинди матур әйберләр, дип сокланучылар да бар икән. Андыйлардан: «Сездә тузан җыеп яткан әйберләр юкмы?» – дип сорап караган. «Һай, җеп эрли торган җиһазларны, патефоннары чүплеккә ыргыттык шул», – дигән җавап кына ишеткән. Сәрия апа әйтүенчә, күбрәк олылар кызыксына, ә яшьләрнең исе китми икән.

Сәрия апа һәрбер экспонатны кадерләп саклый. 56 әйбергә дә үз мәхәббәте аның. Алар бит аңа балачагын, яшьлеген, иң җылы хатирәләрне искә төшерә.

Әнә искереп беткән күмер үтүкләре турында Сәрия апа заманчасыннан да кадерлерәк итеп сөйли. Ни өчен дигәндә, шуның белән мәктәп киемнәрен, галстукларын үтүкләгән ул. Иске лампалар да мәктәпкә бәйле вакыйгаларны яңарта.

– Мин 1960 елда тудым. Укырга кергәндә, ут юк иде. Бер лампа түшәмдә эленеп, икенчесе өстәлдә тора иде. Дәресне шулар яктысында әзерләдек. Тагын бер фонарь бар әле. Әти белән әни малларга башак биргәндә, мин шуның белән яктыртып тора идем. Абыйлар алып кайткан шахта фонаре да бар, – дип сөйли ул. – Самавыр да кадерле. Зәйнәп әбием шуны кайнатып, мәктәптән чәй әзерләп каршы ала иде. Менә бу керосинка астындагы табада ком була иде. Ялкыны чәчелмәсен өчен салына иде ул. Шунда кетердәп тора торган таба бәрәңгесе, тәмле аш пешерә идек. Шикәр ваткычта да әбинең куллары җылысын тоям. Элек шикәр уч төбе кадәр була иде, шуны ватып, ул безгә бүлеп бирә иде. Әбинең комганына караган саен, тәһарәт алып, намаз укыганы күз алдына килә. Көянтә белән ел буе чишмәдән су ташыдык. Зур ләгәндә шушы тимергә ышкый-ышкый кер юа идек. Җәй көне келәт алдына чыгам да кошлар сайравын тыңлап, үзем үстергән чәчәкләргә сокланып, әби-бабайларны, әти-әнине сагынып утырам. Әле ярый берсен дә ташламаганмын. Яз һәм көз тузаннарын сөртеп, кабат урыннарына куям.

Сафиннар ике ул тәрбияләгән, Айнур белән Айдар икесе дә авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган. Аерым яшәсәләр дә, әти-әниләренә ярдәм итеп торалар. Шәһәрдән кайтучы оныклар да музей белән кызыксына. Алар өчен бөтенләй башка дөнья. Сәрия кебек әбиләре булганда, нәсел тамырларын белеп үсәләр. Буыннар үзгәрер, 10–20 елдан монда бөтенләй башка экспонатлар урын алыр. Музейда әле урын җитәрлек.

Сәрия ХАФИЗОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Университет коллективының фәнне үстерүдә аеруча зур казанышларга ирешүе, республиканың агросәнәгать комплексына югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә мөһим өлеш кертүе өчен **«Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының халыкара абруен һәм социаль-икътисади потенциалын, милләтара тынычлыкны һәм татулыкны ныгытудагы мөһим казанышлары өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе **Мөхәммәтшин** Фәрит Хәйрулла улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Театр сәнгатен үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе баш режиссеры **Бикчәнтәев** Фәрит Рәфкать улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Техник фәннәр докторы, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең очу аппаратлары конструкцияләү һәм проектлау кафедрасы мөдире **Гайнетдинов** Владимир Григорьевичка, тарих фәннәре докторы, «Россия ислам институты» югары белем бирү хосусый учреждениесенең системалы теология кафедрасы фәнни хезмәткәре **Ислаев** Фәйзелхак Габделхак улына, биология фәннәре докторы, «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе – Казан биохимия һәм биофизика институтының микроскопия төркеме җитәкчесе, әйдәүче фәнни хезмәткәре **Сальников** Вадим Владимировичка **«Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры **Вәлиев** Айрат Рәсим улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Көмеш Күл төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Кашапова** Дания Таһир кызына, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Василий Петрович Муравьев исемендәге Затон урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Кулагина** Марина Владиславовнага, Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең «4 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Мифтахова** Гөлсинә Гомәр кызына, Казан шәһәре Вахитов районының «СОлНЦе» махсуслаштырылган олимпиада-фәнни үзәге» урта гомуми белем бирү мәктәп-интернаты» аеруча сәләтле укучылар өчен муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең физика укытучысы **Сомов** Алексей Робертовичка, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Зур Күккүз урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Сөләйманова** Наилә Мансур кызына, «Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең музыка укытучысы **Фазылова** Елена Николаевнага, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган Кнәз урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Фәрахова** Рамилә Яхъя кызына, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган Апас урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Хисамова** Альмира Фәтхелислам кызына, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган структур бүлекчәсе милли мәгариф бүлеге әйдәүче фәнни хезмәткәре **Шәкүрова** Мөслимә Мәгъсүм кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Спорт

rubin-kazan.ru

Әлегә хушлашмыйлар

«Рубин»ның баш тренеры Леонид Слуцкий Казаннан китмәячәк. Кала, әмма командасының кайда уйнаячагы билгеле түгел: ФНЛга төшәрме, әллә премьер-лигада калырга рөхсәт бирерләрме? Башкала клубының язмышын Мәскәүдә хәл итәчәкләр. Генераль директор Рөстәм Сайманов үзләрен «корбан» дип атады.

Татар юрап китерер. Узган шимбәдә «Рубин» тамашачысының курыкканы чынга ашты. 2003 елдан бирле премьер-лигада чыгыш ясап, ике мәртәбә чемпион булып танылган, берничә ел дәвамында Европаны шаулаткан команда хәлиткеч матчта «Уфа»га оттырып, сезонны 15 нче урында тәмамлады. Мондый уенны хәтта иң талантлы режиссерлар да уйлап чыгара алмас иде. Башта «Рубин» беренче булып туп кертте. Аннары көндәшләр исәпне тигезләде һәм төп вакытның соңгы минутында алга чыктылар. Инде барысы да бетте дигәндә, Сергей Иванов кунаклар капкасына пенальти билгеләде: Леонид Слуцкийның иң яратмаган хөкемдары аның командасына һич югы бер очко алу мөмкинлеге бирде. Әмма беренче таймда туп керткәч, кулына телефон алып, шатлыгын фотога төшерә башлаган Виталий Лисаковичка бәхет бу юлы арты белән борылды. Ул типкән туп капка баганасына бәрелеп, Казан командасының өметен юкка чыгарды.

Очрашудан соң җанатар сүгенде, футболчылар гафу үтенде. Күз яше күрсәтүчеләр дә булды. Моннан өч ел элек «Рубин»ны коткару өчен чакырылып, беренчесендә бу эшне уңышлы башкарып, аннары җырга-моңга бирелгән, бертуктаусыз хөкемдарлар белән тарткалашкан, футбол кыры өчен җаваплы агрономнарны сүккән, язга чыккач чит ил уенчыларының китүеннән зарланып, кул астындагы уенчылардан өметен өзгән Леонид Слуцкий исә матбугат очрашуына ничек керде, шул килеш чыгып та китте. Ниләр булганны аңлатырга һәм ниләр көтеләсен сөйләргә журналистлар алдына дүшәмбе көнне клубның генераль директоры Рөстәм Сайманов чыкты.

Беренче итеп баш тренер турында сорадылар. Слуцкий калачак. Хәтта команда ФНЛда чыгыш ясаган очракта да Казандагы эшен дәвам итәчәк. «Ул – яхшы белгеч. Сезон нәтиҗәсен аның осталыгы белән генә бәйләү дөрес түгел. Бу очракта ул барысыннан да күбрәк зыян күрде, үзе корбанга әверелде», – диде генераль директор.

Рөстәм Сайманов бүгенге хәлләрнең төп сәбәбе дип чит ил уенчыларының кайтып китүен әйтә. Билгеле булганча, Европаның футбол түрәләре Россиядә чыгыш ясаучы уенчыларга гамәлдәге килешүне туктатып торырга рөхсәт бирде. Мондый мөмкинлектән файдаланып, Казан командасының 6 футболчысы китеп барды. «Безне таладылар», – ди Рөстәм Сайманов. Генераль директор әйтүенчә, Казан клубында очсызрак бәягә чит илдән футболчылар алып, соңрак аларны сатып, акча эшләргә хыялланганнар. Әмма Украинада мәгълүм хәлләр башлангач, барысы да пыран-заран килә. «Ул егетләр белән утырып сөйләштек. Акча түләнәсен, илдә тыныч буласын әйттем. Калырга ризалаштылар. Ә аннары барысын да ташлап кайтып киттеләр. Без бу вакыйгалардан иң зур зыян күргән клуб булдык», – диде ул.

Әлегә исә күзләр Мәскәүгә төбәлгән. 24 майда анда Россия футбол берлеге башкарма комитеты утырышы уза. Әлеге җыелышта премьер-лигада чыгыш ясаучы командалар саны турында фикер алышу була. 16дан 18гә җиткерәләр икән, «Рубин»га тагын бер мөмкинлек бирәчәкләр. Инде юк икән, Казан командасына, кем әйтмешли, җиргә төшеп, барысын да яңабаштан башларга һәм иң көчлеләр сафында уйнау хокукын кабат яуларга туры киләчәк.

– Слуцкий ФНЛга әзер. Әле менә алдагы көнне генә төнгә кадәр алырга мөмкин булган уенчылар турында сөйләшеп утырдык. Премьер-лигада калырга өметләнәбез. Инде төшәбез икән, кабат кайтуны максат итеп куйдык, – диде Рөстәм Сайманов. – ФНЛда уйнау безнең өчен җинаятькә тиң. Шуңа күрә хушлашмыйбыз.

	команда	очко
1	Зенит	65
2	Сочи	56
3	Динамо	53
4	ЦСКА	50
5	Краснодар	50
6	Локомотив	48
7	Ахмат	42
8	Крылья Советов	41
9	Ростов	38
10	Спартак	38
11	Нижний Новгород	33
12	Урал	33
13	Химки	32
14	Уфа	30
15	Рубин	29
16	Арсенал	23

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Бу еллар эчендә дәлилләр дә тупланды. Алар булмаса, фәнни, идеологик эшләр алып бару мөмкин булмас та иде. Җир казучыдан башлап, галимнәргә кадәр рәхмәт. Халыкка рәхмәт! Бу – уртак эшебез. Бу – истәлекле вакыйга. Безнең горурланырлыгыбыз бар. Булдыра торган халык без. Киләчәктә дә шулай булачак. «Без булдырабыз» сүзе болай гына әйтелми бездә. Болгар безнең халыкның ихтыяр көчен, булган халык икәнебезне күрсәтте», – диде ул.

Минтимер Шәймиевтән дә ялкынлырак чыгыш ясаучы Россия мөселманнары Үзәк диния нәзарәте рәисе, мөфти Тәлгать Таҗетдин булгандыр. Дин әһеле халыкны, шайтан чакырмас өчен, кул чапмаска кирәк, дип көлдерде дә, үзгәрмик, дип фәлсәфә дә корды.

– Соңгы арада без бердәйлек (идентичность) турында күп сөйлибез. Ә нәрсә соң ул? Һәркем нинди бар, шундый булырга тиеш, – дип чыгыш ясады мөфти. – Европа илләрендә кем белән яшәргә, кемне нәрсәгә алмаштырырга белмиләр. Ишәккә озын койрык-мөгез өстәп кенә, ул атка әверелми бит. Без Мичурин түгел, без – Аллаһы Тәгаләнең коллары. Аның җирендә яшибез.

> Шуңа да бу бәйрәм – безнең бердәйлекне торгызу көне дә. Аллаһ бөтен халыкларны берләштерде. Бәйрәмнәр күп булган саен, сугышлар да азрак була. Табын корулар күбрәк булган саен, аңлашу да күбрәк. Безнең хаҗ кылу гадәте бар. Бу бәйрәм дә хаҗ кебек. Без бирегә үзебезнең кем икәнебезне исбатларга килдек. Татарны болай да беләләр иде инде. Әмма Болгарны дөньяда белмәделәр. Таныдык та, таныттык та хәзер.

Россия мөселманнары Диния нәзарәте башлыгы Равил Гайнетдинов күбрәк Мәскәүдә көтеләчәк чаралар турында сөйләде. Бәлки әле тантаналы чараларда ил башлыгы Владимир Путин да катнашыр дигән өметен җиткерде.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин исә бирегә килгән һәр кешенең Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешүен теләде. «Россия территориясендә рәсми төстә кабул ителгән тәүге дин ул – ислам. Шуңа күрә дә бу вакыйга безнең барыбыз өчен дә мөһим», – диде ул.

tatarstan.ru

УРТАК ШАТЛЫК

Изге җиргә җан тарта

Бу көнне Болгар җиренә 20 меңләп кеше җыелды. Җан-кан тарткан урынга килү теләген һава торышының көйсезлеге дә баса алмый шул, күрәсең. Халык җыен кысасында оештырылган төрле остаханәләрдә дә катнашты, борынгы тарих шаһиты булып торган корылмалар белән хозурланды, көрәш карады, сыйлардан авыз итте. Бу җәһәттән Болгарны туристларны җәлеп итә торган Татарстанның иң матур урыны дип әйтергә дә тулы хокук бар.

Халык белән аралашканда да, күбесенең Ак мәчетне һәм иң зур басма Коръәнне күрергә килүен аңларга була иде. Ул гына да түгел: Президентны күргәнем юк, дип, әтисенең җилкәсенә менеп, рәсми затларны караучы яшь балалар да очрады.

Күпләр Олы манара янәшәсендәге хәрабәләрне эзләп килгәннәр. Ник дигәндә, бу хәрабәләрдә борынгы таш багана бар. Аңа кулы белән тотынган кешеләрнең хыяллары чынга аша дигән ышану мәгълүм. Хыялсыз кеше юк бит: барысы да ташны сыйпарга омтылды.

> Шунысын әйтим: таштан сорарга һич кенә дә ярамый. Сез чын йөрәктән таштан сорарга тиеш түгел. Безгә дигәнен Аллаһы Тәгалә генә белә һәм бирә! –

дип искәртеп торды кайсыларын янәшәдә генә баскан экскурсовод.

Җил дә вакытсыз исеп, яңгыр-боз да вакытсыз явуга карамастан, ата-бабаларыбыз җиренә килми кала алмадым, ди Яшел Үзәннән Зөфәр абый. Биш автобус кеше килгәннәр, торган урыннарыннан Болгарга кадәр 200 чакрымнан артык юл. «Бу гына куркыта аламы инде? Беренче генә килүем түгел», – диде ул.

Яңгырдан зарланырга кирәкми, ди Башкортстаннан ук килгән Хәмзә хәзрәт Хафизов. «Һава торышын сүгәргә кирәк түгел. Яңгыр ул – бәрәкәт. Яңгыр булгач, икмәк уңа, бай булабыз», – диде ул. Сүз уңаеннан, өстән яуганга борчылырга кирәкми, дип Минтимер Шәймиев тә искәртте. «Яңгыр булгач, бодай үсәчәк», – диде ил агасы.

Гөлфия ханым дүрт баласы белән Саратовтан кадәр килгән. «Ак мәчет, музейларны, Коръән басмасын күрдек. Бер мәлгә үземне Саратовтагы Үкәктә (Алтын Урда шәһәре. – **Авт.**) кебек хис иттем, бирегә дә калкулыктан елгага шундый ук манзара ачыла», – дип уртаклашты ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

dumrt.ru

Президент Рөстәм Миңнеханов һәм Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиевкә Үзәк диния нәзарәтенең «Мөхәммәт рәсүлүллаһ» медале, Милли шура рәисе Васил Шәйхразыевка «Әлһәмду» ордены тапшырылды.

tatarstan.ru

Билбаулы көрәш буенча Дөнья Кубогының финал ярышлары да Болгарда узды. Турнирда 26 илдән 160 көрәшче бил алышты. Батыр исеменә Яшел Үзән егете Фирдүс Зәйнуллин лаек булды. Ул былтыр да батыр булып калган иде.

ЧӘЧКӘЛӘРНЕҢ НИГӘ КИРӘГЕ БАР?

Шөгыль

Ирекнең иркенләп сөйләшергә вакыты да юк. Чәчәк алырга килүчеләрдән чират җыелган. Көн саен шулай икән. Рекламасы-фәләне юк аның, кешеләр бер-берсеннән ишетеп килә. Ә бит эшкә очраклы рәвештә алынган ул. Дөрес, үзе әйтмәсә дә, хатынының исеме белән бәйле түгел микән бу шөгыле? Без шулай дип фаразладык.

– Өйләнешкәч, хатыным Гөлчәчәк белән киңәштек тә чәчәк үстереп карарга булдык, – дип искә ала 30 яшьлек эшмәкәр. – Белемем буенча икътисадчы мин. Авылда төпләнеп калгач, үз эшебезне ачып карыйсы иттек. Башта кыенрак булды, әмма артка юл юк иде инде. Әти-әнием гади кешеләр: әти – машина төзәтүче, әни пешекче булып эшли. Шуңа да кемнәндер ярдәм көтеп утыру оят булыр иде. Янәшәмдә хатынымның терәк булуы ярдәм итте. Бар эшне Гөлчәчәк белән бергә башкарабыз. Кемнедер яллап эшләтү өчен түләргә кирәк. Үзең эшләгәч, бар нәрсәнең тәртибен беләсең. Чәчәкләр дә яратканны сизә.

Дөрес, ярату гына җитми, тәвәккәллек тә кирәк, ди Ирек. Эшли-эшли әнә шундый фикергә килгән ул. Баштарак акчаны янга калдыру өчен туфракны үзе әзерләгән. Хәзер инде эшләре җайлангач, сатып кына алабыз, ди.

– Эшне лалә үстерүдән башладык. Аны ноябрьдә утырта башлыйбыз. Кышын Кукмарада лаләне без генә үстерәбез. Март башларында инде сатып та бетерәбез. Аннары башка чәчәкләргә чират җитә. Халык бигрәк тә петуния ярата. Бер иярләнгән кешеләр ел саен безгә киләләр, – ди Ирек.

Чәчәкләрне дә төрләндергән Ирек. Баштарак гел петуния генә сатса, хәзер араларында дәлия (георгин), бәрхет гөл (бархатцы), канәферләр дә бар. Бер кырыйга гаиләсе өчен кыяр да утыртып куйган. Инде уңышын күптән алганнар. Помидор, кәбестә, борыч, баклажан кәлшәләре дә бар. Алары күп түгел. Яшелчә үстерүчеләргә дәүләт ярдәм вәгъдә итсә дә, Ирекнең чәчәктән аерыласы килми. Киләчәктә эшен тагын да җәелдермәкче.

Үз-үзенә ышанган егет дип чыктык без аның яныннан. Сатылып бетмәсә, нишләтермен, дип тә борчылмый ул. Баксаң, җиде ел эшләп, бер генә чәчәге дә әрәм булмаган. Барысын да алып бетерәләр, ди.

– Бәхетемне туган якта таптым. Эшемне яратып башкарам. Әти-әнием исән-сау, гаиләм бар. Хатыным белән ике ул үстерәбез. Бакчамда күзләрне иркәләп чәчәкләрем үсә, – ди ул. – Һәр эшнеке кебек, чәчәк утыртуның да үз чыгымнары бар. Әмма аны санап тормыйбыз инде хәзер. Булганына сөенәбез. Иң мөһиме – райондашларым чәчәкләребезне ярата. Алардан рәхмәт ишетүне бернигә дә алыштырып булмый.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7061 данә
Гомуми тираж – 16033 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 271

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+